Газета 1931 елның 1 маеннан бирле чыга

# Туган як

Чүпрәле районы газетасы (“Родной край” газета Дрожжановского района)

7 сентябрь, 2018 ел

ГАЗЕТАНЫҢ ЭЛЕКТРОН ВЕРСИЯСЕ: CHUPRALE-ONLINE.RU

№56 (9290)

## КИЧӘ.БҮГЕН.ИРТӘГӘ.

### Өстәмә сайлаулар узачак

2018нче елның 9 сентябрендә муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына өстәмә сайлаулар узачак. Безнең районда сайлаулар Иске Чүпрәле, Кече Чынлы, Матак, Марс, Иске Кәкерле һәм Шланга авыл җирлегендә үтә. Сайлау участоклары 7.00–20.00 сәгатькә кадәр эшли.

### Авыл җирлекләренә - яңа машина

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов муниципаль районнар арасындагы республика смотр-бәйгесендә җиңүчеләргә машина ачкычлары тапшырды. Бәйгегә барысы 200дән артык гариза кергән. Республика смотр-бәйгесе 2010 елдан башлап уздырыла.
Шулай итеп, муниципаль районнар 93 “внедорожник” алды. Казан – 4 микроавтобуслы, Чаллы 3 микроавтобуслы булды. Агымдагы елда яңа машиналы булу бәхете Матак һәм Иске Шәйморза авыл җирлекләренә “елмайды“.

### “Ана капиталы“ сертификатын-электрон формада

Моның өчен Дәүләт хезмәтләре порталы яки Пенсия фонды сайтындагы шәхси кабинетның аша гариза тапшырырга кирәк. Аннары теркәлү урыны буенча пенсия бүлегенә барып документларны тапшырырга туры киләчәк. Документларны биргәннән соң, сертификатны алу өчен кабат пенсия бүлегенә килү мәҗбүри түгел. Электрон сертификат автомат рәвештә гариза тапшыручының шәхси кабинетына киләчәк. Сертификат белән бергә “Ана капиталы“ турында бар мәгълүмат тупланган электрон документ та биреләчәк. Бу рәсми кәгазьләрне бастырып алырга, экраннан карап өйрәнергә дә мөмкин.

### Ипигә бәя артырга мөмкин

Быел көз, октябрь аенда, Россиядә ипигә бәя 10 процентка артырга мөмкин. "Руспродсоюз" берлегендә валюта курсы үзгәрү һәм 2018 елда уңыш кимүгә бәйле рәвештә, ашлыкка бәя артуын әйткәннәр. Мәсәлән, 3 нче классны 1 кг бодай хәзер 12 сум тора. Ә август башында ул 10 сум гына иде. Аналитиклар фаразы буенча, сентябрь уртасыннан башлап, онны сату бәясе килосына 18-18,5 сумга җитәргә мөмкин. Август башында 1 кг он өчен 16 сум түлисе иде.
Ипи пешерүчеләр һәм кондитерларның Россия гильдиясендә продукциягә сату бәясе артырга мөмкин, ләкин күпкә түгел, дигәннәр.

### Иске Чокалыда авыл бәйрәме

Шимбә, 8 сентябрьдә, Иске Чокалыда Авыл бәйрәме узачак. “Авыл көнe“ндә булачак чаралар:
10.00–милли фольклор “Чәй суында”. (Үтәчәк урыны–кизләү яны).
10.30–сүүткәргеч челтәрен ачу тантанасы. (Мәдәният йорты алды).
14.00–Корбан ашлары. (Мәктәп ашханәсе).
18.00–Мәдәни күңел ачу чаралары. (Үзәк мәйдан).
21.00–Бәйрәм салюты.
Бәйрәмгә рәхим итегез! 6+

### Хезмәтен хөрмәтләп

Мәдәният өлкәсендә квалификацияле белгечләр хәзерләүгә зур өлеш керткәне өчен “Чүпрәле тармаклы технологияләр техникумы” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Арифҗан Адиҗан улы БАКИРОВ** Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгының Мактау Грамотасы белән бүләкләнде.

## КӨН ВАКЫЙГАСЫ

# ГОРОДИЩЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА



**ГОРОДИЩЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫНА 26 САБЫЙ ЙӨРИ. Автор фотосы.**

**Городище авылындагы балалар бакчасы быел республика программасы буенча төзекләндерелде. Һәм ул шушы көннәрдә, ачылды. Әлеге вакыйга биредә эшләүче коллектив, сабыйлар, әти-әниләр, авыл халкы өчен дә зур бәйрәмгә әверелде. Балалар бакчасының капиталь төзекләндерелүе аның 30 еллык юбилеена да туры килде.**

**Гөлия ФӘИЗОВА**

Ачык, матур төсләре белән ерактан ук балкып торучы бакча һәркемне үзенә җәлеп итә. Зур коллективның сөенечен бу көнне Марат Гафаров һәм башка кунаклар да уртаклашты. Бакчаның тышкы, эчке ягы да танымаслык булып үзгәргән. Бүлмәләрнең стеналары да күзне иркәләүче матур төсләргә буялган, яңа пәрдәләр, матур шкафлар–барысы да күз явын алырлык. Ишекләр, сантехника, җылылык системасы, тәрәзәләр – өр-яңа. Хәтта проект сметасына кертелмәгән кайбер эшләрне дә башкарганнар төзүчеләр.

Бакча мөдире Елена Мутина балалар, авыл өчен зур бүләк ясаган Татарстан Хөкүмәтенә, район җитәкчелегенә, “Созидание” оешмасының директор урынбасары Марат Низамовка, ярдәм кулы сузган кешеләргә, “Тус” җәмгыяте җитәкчесе Николай Угасловка олы рәхмәтләрен җиткерде.

Балалар бакчасында бүгенге көндә 26 сабый тәрбияләнә, төрле яшьтәге балаларны туплаган ике төркем эшли.

Марат Гафаров та сабыйларның сәламәт, акыллы, талантлы булып үсүләрен теләде. Төзелешкә актив өлеш кертүчеләрне Рәхмәт хатлары белән бүләкләде. Юбилейларын котлап бакчага бүләк тапшырды.

–Без эшкә сөенеп киләбез,-диләр ясле-бакча хезмәткәрләре. –Бөтен яклап уңайлыклар тудырылган, эшләве рәхәт.

Әти-әниләр дә ул-кызлары тәрбияләнәчәк заманча төсмер алган балалар бакчасына булган соклануларын яшермиләр, җитәкчеләргә рәхмәтләр әйтәләр.